ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.11.2018 Балык Бистәсе штп. № 266пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибе турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 19 ноябрендәге XXXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1.Кушымта рәвешендә теркәлә торган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) сайлап алу буенча конкурс үткәрү Тәртибен (алга таба – Тәртип);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составын

расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүнеТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары В.И.Токрановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018 елның
26 ноябендәге 266пи номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) сайлап алу буенча конкурс үткәрү Тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 19 ноябрендәге XXXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә эшләнде һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы муниципаль милектәге җир кишәрлегендә яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлегендә урнашкан очракта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) (алга таба – идарәче) сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибен билгели.

II. Идарәче сайлап алу конкурсын үткәрү

2.1. Идарәчене сайлап алу конкурсын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) сайлап алу буенча конкурс комиссиясе төзелә (алга таба – конкурс комиссиясе).

Конкурс комиссиясе составына Башкарма комитет вәкилләре, килештерү буенча – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Балык Бистәсендәге органнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районында җирле үзидарәнең бүтән органнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы эшкуарлык берләшмәләре вәкилләре керә.

Конкурс комиссиясе составы Башкарма комитет тарафыннан раслана.

2.2. Сайлап алу конкурсын үткәрү шартлары һәм сроклары турындагы хәбәр (алга таба – мәгълүмат хәбәре) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – муниципаль районның рәсми сайты) конкурслы сайлап алуны үткәрү датасына кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

2.3. Мәгълүмат хәбәрендә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

а) конкурсны оештыручының исеме, урнашу урыны: конкурсны оештыручының почта адресы, электрон почта адресы, контакт телефоны номеры, җаваплы вазыйфаи заты;

б) идарәче сайлап алына торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы турында мәгълүматлар;

в) конкурста катнашучыларга куела торган таләпләр;

г) конкурста катнашучылар тәкъдим итәргә тиешле гаризаларны һәм документларны тапшыру ысуллары, срогы, урыны һәм тәртибе;

д) конкурслы сайлап алуны үткәрү датасы.

III. Конкурс комиссиясе әгъзаларынының вәкаләтләре.

Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин ителеше.

3.1.Конкурс комиссиясе рәисе:

а) конкурс комиссиясе эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

б) конкурс комиссиясенең эш регламентын аныклый;

в) конкурс комиссиясенең чираттагы утырышын үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгели;

г) конкурс комиссиясе утырышының көн тәртибен раслый;

д) конкурс комиссиясе утырышларында рәислек итә;

е)конкурс комиссиясен җирле үзидарә органнарында һәм кызыксынучы оешмаларда тәкъдим итә.

3.2.Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда аның вәкаләтләрен конкурс комиссиясе рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

3.3.Конкурс комиссиясенең эшче органы функцияләрен Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге гамәлгә ашыра.

Конкурс комиссиясе эшчәнлегенең оештыру-техник, методик һәм бүтән тәэмин ителешен Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге гамәлгә ашыра.

3.4. Конкурс комиссиясенең эшче органы конкурс комиссиясе утырышларын хәзерләүне оештыра, шул исәптән:

конкурс комиссиясе утырышының көн тәртибе проектын хәзерләүне, конкурс комиссиясе утырышларына материаллар һәм конкурс комиссиясенең карарлары проектларын таратуны тәэмин итә;

конкурс комиссиясе әгъзаларына утырышларны үткәрүнең датасы, вакыты һәм урыны, шулай ук конкурс комиссиясе утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсъәләләр турында хәбәр итүне тәэмин итә;

конкурс комиссиясе утырышына хәзерләнү өчен кирәк булган, шулай ук җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга җибәрәсе материалларны ала.

3.5. Конкурс комиссиясе сәркатибе утырыш беркетмәсен алып бара һәм конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерә.

## IV. Конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм аны оештыру

4.1. Конкурс комиссиясе утырышлары муниципаль дәрәҗәдәге тиешле сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен конкурслы сайлап алуда катнашуга гаризалар керүгә карап уздырыла.

4.2. Конкурс комиссиясе утырышларында киңәш бирү хокукына ия тавыш белән Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары, башкарма хакимият федераль органнарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районындагы территориаль органнары вәкилләре катнаша ала.

4.3. Конкурс комиссиясе әгъзаларына һәм кызыксынучы башка затларга конкурс комиссиясе утырышын үткәрү урыны, датасы һәм вакыты хакында утырышны үткәрү датасына хәтле бер эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә. Белдерү хәбәре ул җибәрелгән зат тарафыннан алынганлыкны ышанычлы билгеләргә мөмкинлек бирүче теләсә нинди ысул белән җибәрелә, шул исәптән факсимиль элемтә, телефонограмма яисә электрон почта аша.

4.4.Конкурс комиссиясе утырышы яртысыннан ким булмаган санда әгъзалары катнашканда вәкаләтле санала.

Конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан үзенең вәкаләтләрен бүтән затка тапшыру, әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында каралган очрактан гайре, рөхсәт ителми.

4.5. Конкурс комиссиясенең утырыш көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча карары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Конкурс комиссиясенең карары, аның өчен тавыш бирүдә катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары санының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән булып санала. Конкурс комиссиясенең һәрбер әгъзасы тавыш биргәндә бер тавышка ия.

4.6. Тавышлар саны тигез булган очракта конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

4.7. Конкурс комиссиясе әгъзалары тавыш бирү нәтиҗәләреннән аерылып торган аерым фикерләрен язмача рәвештә белдерергә хаклы. Әлеге факт беркетмәдә чагылдырылырга тиешле, ә тиешле документ конкурс комиссиясе утырышы материалларына теркәп куела.

4.8. Конкурс комиссиясе карары барлык комиссия әгъзалары имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәдә конкурс комиссиясе утырышында каралган мәсьәләләр һәм алар буенча кабул ителгән карарлар чагылыш таба.

## V. Конкурслы сайлап алуның идарәче сыйфатында сайлап алыну хокукына дәгъва кылучы катнашучыларына таләпләр

Конкурслы сайлап алуның муниципаль дәрәҗәдәге тиешле сәнәгать мәйданчыгының идарәчесе сыйфатында сайлап алыну хокукына дәгъва кылучы катнашучысы түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

а) юридик затлар өчен – оештыру-хокукый формада хуҗалык ширкәте яки җәмгыяте, крестьян (фермерлык) хуҗалыгы, хуҗалык хезмәттәшлеге,

җитештерү кооперативы, дәүләти яки муниципаль унитар предприятиесе, ассоциацияләр (шул исәптән коммерцияле булмаган хезмәттәшлек) оештыру;

б) индивидуаль кәсәбчеләр өчен – законнарга ярашлы рәвештә индивидуаль эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәлүе;

в) Россия Федерациясе салым органнарында учетка басу;

г) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бирәчәкләрнең булмавы;

д) юридик зат яңабаштан үзгәртеп кору, бетерү, бөлгенлек процессында түгел, ә индивидуаль эшмәкәр индивидуаль эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатмаган.

## VI. Конкурслы сайлап алуны үткәрүне оештыру

6.1. Конкурслы сайлап алуда катнашучы муниципаль районның рәсми сайтында белдерү хәбәре урнаштырылган көннән соң 10 календарь көн эчендә Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлегенә конкурс комиссиясе каравы өчен түбәндәге документларны тапшыра:

а) конкурслы сайлап алуда катнашуга, әлеге Тәртипкә кушымта итеп бирелгән формага туры китереп, язмача рәвештә гариза (алга таба – гариза);

б) гамәлгә куючы документларның һәм аларда булган үзгәрешләрнең күчермәләре (юридик затлар өчен);

в) салым органыннан Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар,штрафлар, процентлар буенча бирәчәкләре юклыгын раслаучы гариза бирү көненә кадәр 30 календарь көн һәм аннан кимрәк вакыт эчендә бирелгән белешмә;

г) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы үсешенең бизнес-планы;

д) юридик зат җитәкчесенең (индивидуаль эшмәкәрнең) яки юридик зат (индивидуаль эшмәкәр) исеменнән эш йөртүче башка затның вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе;

Конкурслы сайлап алуда катнашучы тарафыннан үз инициативасы белән юридик заларның Бердәм дәүләт реестрыннан, индивидуаль эшмәкәрләрнең (индивидуаль эшмәкәр өчен) Бердәм дәүләт реестрыннан Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлегенә мөрәҗәгать итү датасына кадәр 30 календарь көн һәм аннан кимрәк вакыт эчендә бирелгән өземтә тәкъдим ителергә мөмкин.

Гариза бирүче тарафыннанәлеге пунктның"в" пунктчасында каралган документ, шулай ук юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан (юридик затлар өчен) өземтә, индивидуаль эшмәкәрләрнең (индивидуаль эшмәкәр өчен) Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә тапшырылмаган очракта Башкарма комитет күрсәтелгән документларны закон нигезендә дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органында ведомствоара мәгълүмат алмашу тәртибендә соратып алдырта.

Конкурслы сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган барлык документлар бөтен пунктлары буенча да тутырылган булырга тиеш

(мәгълүматлар булмаган очракта сызык куела). Бетерүләр һәм төзәтүләр, мөһер белән (мөһер булганда) таныкланган һәм вәкаләтле зат (юридик затлар өчен) имзасы белән расланган яисә үз кулы белән раслаган (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) төзәтүләрдән гайре, рөхсәт ителми. Гариза һәм документларның барлык битләре дә номерланган булырга тиеш. Документларның күчермәләре аңа вәкаләте булган затның имзасы һәм гариза бирүченең мөһере (юридик затлар өчен) (мөһер булганда) яисә үз кулы белән (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) расланган булырга тиеш.

Гариза һәм документлар тегелгән һәм, соңгы документның арт ягында битләрнең гомуми санын күрсәтеп, аңа вәкаләте булган затның имзасы һәм гариза бирүченең мөһере (юридик затлар өчен) (мөһер булганда) яисә үз кулы белән (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) расланган булырга тиеш.

6.2. Документларны кабул итү срогы дәвамында Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге сайлап алу конкурсында катнашучыларга документлар хәзерләү мәсьәләләре буенча киңәшләр бирүне оештыра.

6.3. Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлегенә кергән документлар керү көнендә номерланган, шнурланган һәм Башкарма комитет мөһере белән таныкланган документлар учеты журналында теркәләләр.

6.4. Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлегенә кергән документлар документлар кабул итү (шул исәптән почта аша да) әлеге Тәртипнең 6.1. пунктында күрсәтелгән срогы тәгәлләнгәннән соң теркәлмиләр һәм сайлап алу конкурсында катнашуга үткәрелмиләр.

6.5.Документлар документлар кабул итү срогы беткәнче конкурслы сайлап алуда катнашучының башкарма комитетның территориаль үсеш бүлегенә тиешле мөрәҗәгать юллау ысулы белән кире чакыртып алынырга мөмкин. Чакыртып алынган документлар конкурс комиссиясе тарафыннан карауга тәкъдим документлар санын ачыклаганда исәпкә алынмый.

6.6. Конкурслы сайлап алуда катнашучы сайлап алу конкурсында катнашуга үткәрелми шул очракта, әгәр:

конкурслы сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртипнең V бүлегендә тәгаенләнгән таләпләргә туры килмәсә;

конкурслы сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 6.1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим итү бурычы гариза бирүчегә йөкләнгән документларны тапшырмаган (яисә тулы күләмдә тапшырмаган) булса;

документлар сайлап алу конкурсында катнашучы тарафыннан факс яки электрон почта аша җибәрелгән булса;

документлар керүдә әлеге Тәртипнең 6.4 пунктында каралган документлар кабул итү срогы бозылган булса.

6.7. Конкурслы сайлап алуга тапшырылган документлар кире кайтарылмый.

6.8. Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге тарафыннан документлар конкурс комиссиясе каравына документлар кабул итү срогы тәмамланган көннән соң 3 эш көне эчендә тапшырыла.

## VII. Конкурслы сайлап алуны үткәрү процедурасы.
## Конкурслы сайлап алуга нәтиҗә ясау.

7.1.Конкурс комиссиясе документларны карый, әлеге Тәртипнең 7.2 пунктында куелган критерийлар буенча муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерүнең бизнес-планын бәяли.

Документларны карау процессында килеп туган сораулар фән һәм техниканың төрле өлкәләрендә махсус белемнәр таләп итсә, конкурс комиссиясе утырышларына әлеге сорауларны аңлату өчен экспертлар, белгечләр, галимнәр һәм башка кызыксынучы затлар чакырыла.

7.2. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерү бизнес-планын бәяләү критерийлары булып тора:

а) тәкъдим ителүче муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерү бизнес-планының муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын төзү максатларына һәм аның территориясендәге икътисади эшчәнлек төрләренә туры килүе;

б) тәкъдим ителүче муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерү бизнес-планының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 27 августындагы “Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәт ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектларының аккредитациясе турында” 616 номерлы карары белән билгеләнгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы эшләве чагыштырма күрсәткечләренең минималь кыйммәтләренә туры килүе;

в) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерүне тормышка ашырганда заманча технология һәм идарә итү чишелешләрен куллану;

г) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерүне тормышка ашыру процессында җирле бюджет чыгымнарын финанслауның башка чыганакларына планлаштырылган алмаштыру.

7.3. Конкурс комиссиясенең һәрбер әгъзасы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерүнең бизнес-планын бәяләүне биш баллы шкала буенча (1 баллдан 5 кә кадәр) әлеге Тәртипнең 7.2 пунктында каралган критерийлар буенча гамәлгә ашыра.

Конкурс комиссиясе әгъзаларының һәрберсе куйган билге нигезендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерүнең бизнес-планын бәяләүнең һәр критерие буенча уртача балл чыгарыла.

Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерүнең бизнес-планын бәяләүнең барлык критерийлары буенча балларның иң күп гомуми санын җыйган конкурслы сайлап алуда катнашучы җиңүче итеп танылa.

Баллар саны тигез булганда гаризаны бүтәннәрдән алданрак биргән конкурслы сайлап алуда катнашучы җиңгән була.

7.4. Конкурслы сайлап алуда катнашуга бер генә катнашучыдан гариза кергән очракта гаризасы әлеге Тәртип таләпләренә туры килгән катнашучы конкурслы сайлап алуда җиңүче булып танылa.

7.5. Конкурс комиссиясенең утырышы әлеге Тәртипнең 6.8 пункты нигезендә конкурс комиссиясенә документлар тапшырылган көннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә. Конкурс комиссиясе утырышы үткәрелгән көннән соң 3 эш көне эчендә конкурс комиссиясенең карары конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары кул куйган

утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән беркетмә кул куелган көннән соң 1 эш көне дәвамында муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла. Конкурслы сайлап алуның һәрбер катнашучысына Башкарма комитет тарафыннан кабул ителгән карар хакында кабул ителгән көннән соң 5 эш көне эчендә язмача рәвештә хәбәр ителергә тиеш.

## VIII. Конкурс комиссиясе карарларына шикаять белдерү тәртибе

Гариза бирүче законда каралган тәртиптә конкурс комиссиясе карарларына шикаять белдерергә хокуклы.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) сайлап алу буенча конкурс үткәрү Тәртибенә кушымта

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә “________” муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) конкурслы сайлап алуда катнашуга ГАРИЗА

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) сайлап алу буенча конкурс үткәрү Тәртибен, “_________”муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) конкурслы сайлап алуны үткәрүнең шартлары һәм сроклары турындагы мәгълүматны өйрәнеп,

____________________________________________________________________________

(оешманың (индивидуаль эшмәкәрнең) – конкурста катнашучының тулы исеме)

____________________________________________________________________________

(дәүләт теркәвенең датасы һәм номеры)

____________________________________________________________________________

(юридик һәм факттагы адрес)

____________________________________________________________________________

(телефон, факс, электрон почтаның адресы)

_____________________________________________________________________ __йөзендә

(җитәкче вазыйфасының аталышы һәм җитәкченең Ф.И.А.и.)

югарыда күрсәтелгән документлар белән билгеләнгән шартларда конкурста катнашу турында хәбәр итә һәм әлеге гаризаны җибәрә.

Әлеге гариза белән шуны раслыйбыз: аңа –

____________________________________________________________________карата_

(оешманың (индивидуаль эшмәкәрнең) – конкурста катнашучының тулы исеме)

яңабаштан үзгәртеп кору, бетерү, бөлгенлек процедуралары үткәрелми, эшчәнлеге туктатылып тормады, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы юк.

Әлеге гариза белән тәкъдим ителгән мәгълүматның дөреслегенә гарантия бирәбез.

Әгәр___________________________________________________________________________

(оешманың (индивидуаль эшмәкәрнен) – конкурста катнашучының тулы исеме)

билгләнгән тәртиптә конкурсның җиңүчесе булып танылса, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерү бизнес-планының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 27 августындагы "Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәт ярдәме күрсәтү инфраструктурасы субъектларының аккредитациясе турында" 616 номерлы карары белән билгеләнгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы эшләвенең чагыштырма күрсәткечләренең минималь кыйммәтләренә идарәчене сайлау вакытыннан алып 1 ел эчендә җитүен тәэмин итү буенча үзебезгә йөкләмә алабыз.

Әлеге гаризага опись нигезендә ______биттә документлар теркәлә.

Оешма җитәкчесе (индивидуаль эшмәкәр) _____________________________________________

(имза) (Ф.И.А.и.)

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 26 ноябрендәге
266пи номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен (идарәче компаниясен) сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Исланов Роман Леонидович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, конкурс комиссиясе рәисе |
| Токранов Вячеслав Иванович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары |
| Гатиятов Дилүс Харисович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы, конкурс комиссиясе сәркатибе |

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Вафин Фәрит Мансурович | рәис урынбасары – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының бүлек башлыгы (килештерү буенча) |
| Мингалиев Марат Зиннурович | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалы һәм азык-төлек министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килештерү буенча) |

| | |
|---|---|
| Хәсәнов<br>Рәүф Ногманович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге башлыгы |
| Ногманова<br>Илсия Мәликовна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килештерү буенча) |
| Миндубаев<br>Илдар Илдусович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы урынбасары (килештерү буенча) |
| Әсләмов<br>Хәлил Гарәфиевич | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килештерү буенча) |
| Дормидонтов<br>Руслан Олегович | районның эшмәкәрләр берләшмәсе вәкиле (килештерү буенча) |
| Фатихов<br>Минневазыйх Хаҗипович | Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе, филиал директоры – “Татмедиа” АҖ нең “Сельские горизонты” (“Авыл офыклары”) гәҗитенең баш мөхәррире (килештерү буенча) |